СОВЕТ КУГУНУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУНЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
31 октября 2023 года

**КАРАР**
№ 85

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (ижтимагый фикер алышулар) уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

28.09.2023 елның №02-08-01-2023/Прдп 307-23-20920011номерлы “Гавами тыңлаулар (ижтимагый фикер алышулар) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында”гы карарга карата протестка таянып, “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” һәм “России Федерациясендә тимер юл транспорты турында” Федераль Законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында” 29.12.2022 елның 612 номерлы Федераль Законга нигезләнеп, Куныр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Куныр авыл җирлеге Советының 28.05.2020 елның 148 номерлы карары белән расланган (29.06.2022 елның 50 номерлы карарындагы үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 3 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 нче пунктча өстәргә:

4) генераль планнар проекты, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проекты, территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проекты, күрсәтелгән документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, Шәһәр төзелеше Кодексы һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш.

1.3.Нигезләмәнең 13 статьясының 5 абзацында «район Уставы» сүзтезмәсен «торак пункт Уставы» сүзтезмәсе белән алыштырырга, «район Советы» сүзтезмәсен «торак пункт Советы»сүзтезмәсе белән алыштырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә baltasi.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзекләндерү, төзелеш, хокукларны яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә (комиссия рәисе Р.О.Егоров).

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Куныр авыл җирлеге башлыгы Р.О.Егоров